КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

09.07.2024 №148-п

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының аерым боерыкларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 20 февралендәге 190 номерлы карарын үтәп, БОЕРЫК БИРӘМ:

1. «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган «Республика Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенә онлайн-редакция булдыруга һәм сайтны һәм җиһазларны яңартуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2023 елның 29 августындагы 160-п номерлы боерыгы белән расланган «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган «Республика Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенә онлайн-редакция булдыруга һәм сайтны һәм җиһазларны яңартуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә, 17 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Субсидия бирүнең нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешүне һәм субсидия бирүнең нәтиҗәсенә китергән тиешле чараның төгәлләнү фактын чагылдыра торган вакыйгаларны мониторинглау (контроль нокта) Россия Федерациясе Финанс министры билгеләнгән тәртиптә башкарыла.».

2. «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты исеменнән гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган дәүләт бюджет учреждениеләренә вакытлы матбугат басмаларында сайлауларны һәм референдумнарны яктыртуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү

максатларында Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^{1}$ статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2024 елның 24 маендагы 117-п номерлы боерыгы белән расланган «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты исеменнән гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган дәүләт бюджет учреждениеләренә вакытлы матбугат басмаларында сайлауларны һәм референдумнарны яктыртуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^{1}$ статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләүнең кушымта итеп бирелә торган тәртибенә, 17 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Субсидия бирүнең нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешүне һәм субсидия бирүнең нәтиҗәсенә китергән тиешле чараның тәгәлләнү фактын чагылдыра торган вакыйгаларны мониторинглау (контроль нокта) Россия Федерациясе Финанс министры билгеләнгән тәртиптә башкарыла.».

3. Әлеге боерык 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Җитәкче А.С. Сәлимгәрәев